**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2019 елның 1 ноябре №242

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында (Бишнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 августындагы 181 номерлы, 2019 елның 10 апрелендәге 223 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Бишнә авыл җирлеге Советы карары (Бишнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 августындагы 181 номерлы, 2019 елның 10 апрелендәге 223 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Бишнә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (Бишнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 августындагы 181 номерлы, 2019 елның 10 апрелендәге 223 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статья:

1.1) 17 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда торак пунктта яки җирлектә яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия халкының яртысыннан артыграгы катнашканда вәкаләткә ия була. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыграк бер үк вакытта катнашу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән алып бер айдан дә артмаган вакыт эчендә үткәрелә, ул Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмый. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә килесе этапларда

катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргән булса, кабул ителгән дип санала».

1.2) 17 статьяның 3 өлешендәге алтынчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) авылара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;»;

2. Әлеге Карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълумат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълумат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы).

4. Әлеге Карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Зеленодольск районы Бишнә авыл җирлеге башлыгы Фатхуллин И.М. йөкләргә.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**